# НАУКА И ШКОЛА

# ФӘН ҺӘМ МӘКТӘП

ЕЖЕМЕСЯЧНЫЙ
НАУЧНО-
МЕТОДИЧЕСКИЙ
ЖУРНАЛ

09'06



# КАРГА БОТКАСЫ ЯКИ КАРГА ТУЕ

*Г. Камалиева, ТӘһСИ аспиранты*

Борынгы төркиләр, башка күп халыклар кебек үк, яз җитүен түземсезлек белән көтеп алган, аны тизләтергә тырышкан.

Россиянең урта полосасы, шул исәптән Идел буе татарлары яшәгән җирләрдә дә май аенда җылы яктан кошлар кайта башлаган. Бу күренешне яз җиту, җирнең уянуы белән бәйләп караганнар. Бу якларга беренче булып килүче кара каргалар яз хәбәрчеләре булган. Борынгылар язны кошлар алып кайта дип ышанганнар. В.Я. Пропп рус халкында язны каршы алу йоласы турында болай дип яза: "... бәйрәмне "каршы алу" сүзе белән атау төгәл үк түгел, язны китерәләр. Бу йоланың килеп чыгуын аңлау катлаулы түгел: борынгы игенче ел фасыллары алмашынуның закончалыкларын ахырына кадәр аңламаган. Шуңа күрә, кыш мәңге дәвам итеп, яз җитмәскә мөмкин дип уйлаганнар. Шундый бәла килмәсен өчен, язны чакырып, аны йолалар ярдәмендә тизрәк җиткерергә тырышканнар" (6, 37 б.).

Яз җитүне кошлар килү белән бәйләп аңлату күп халыкларга хас күренеш. Ул славян халыкларда да, төркиләрдә дә, башка халыкларда да булган.

Рус халкы яз җитүен түгел, ә кошлар кайтуын тизләтергә омтылган. Һәм язны чакыру кошларны чакыруга кайтып калган. Кошлар кайту белән язның килүе гарантияләнгән. Кошлар тизрәк кайтсын өчен, камыр тургайлар пешергәннәр. Балалар, камыр кошларны тотып, койма башларына, башка биек урыннарга менгән, аларны җеп белән җил тирбәтә торган урыннарга элеп куйганнар. Камыр кошларны күккә чөеп уйнаганнар. Ягъни кошлар кайтсын өчен, аларның кайтуын сурәтләгәннәр (6, 38 б.).

"Тургайларны" гаиләдәге кеше санынча пешергәннәр, һәр кеше үзе ясап чакырган, яз һәр кеше өчен килергә тиеш булган. XIX йөздә пешкән "тургайларны" балалар чөеп уйнаса, борынгырак заманнарда һәркем үз кошын үзе чөйгән, "яки очырган" (8, 40 б.).

Хәтта җылы якларда, мәсәлән Иранда да, яз җитүне кошлар белән бәйләп караганнар. Иранда язны чакыру бәйрәмендә язга, яз һәм җылы алып килүче кошларга, бигрәк тә ләкләккә (аистка) мактау җырлаганнар (5, 37 б.).

Татар халкында язны кара карагалар алып килә дигән ышану булган. Шуңа күрә дә кара каргаларны хөрмәтләп, яз көне "карга боткасы" йоласы уздырылган. И.Н. Надыров "карга боткасы" турында болай дип яза: "Карга боткасы" - ритуал уеннар, такмазалар, "тылсымлы" әйтешләр ярдәмендә язның, кояшлы җылы көннәрнең тизрәк килүен теләп, табигать көчләренә эндәшү, кырда пешерелгән ботканы җиргә сибеп, җир-ананы хөрмәтләү, явыз рухларны куалау йоласы (4, 72 б.).

"Карга боткасы" яки "карга туе" йоласы борынгырак заманнарда ничек үткәрелүе турында мәгълүматлар сакланмаган. Фольклорчы галимнәр Р.М. Мөхәммәтҗанов, Р.Ф. Ягъфәров, этнограф галимә Р.К. Уразманова, диалектологчы галимнәр Ф.С. Баязитов, Д.Б. Рамазанова һәм башкаларның хезмәтләрендә әлеге йола турында мәгълүматлар бар. Әмма алар бары XX йөздә җыелган материаллар гына. Шуңа күрә йоланың тәүге функциясе онытыла барып, ул балаларның һәм яшьләрнең күңел ачуына гына кайтып кала.

Карга туе кара карагалар килгәч үткәрелгән. Карга боткасыннан карагалар өчен өлеш чыгарылган. Бу көнне яшьләр яки балалар өй саен "карга боткасы" өчен ярма, май, он, йомырка җыйган. Р.Ф. Ягъфәров балаларның куллары белән карга канат каккан шикелле кыланып урам буйлап йөгереп, халыкны бәйрәмгә чакырулары турында әйтә. Галим йоланың безнең көннәргә кадәр килеп җиткән текстларын шул чакырулар, сөрән салулар дип карый (9, 117 б.).

Бу текстларны Башкортстан районы авылларында Р.М. Мөхәммәтҗанов язып алган:

Карга әйтә: карр, карр,
Туем җитте - барр, бар,
Ярма, күкәй алып бар,
Сөт-маеңны тагын ал,
Әнәй, итең салып барр!
Барр, барр, барр!

Яки:

Хуҗалар, хуҗалар, өйдәмесез?
Карга туе - беләмесез?
Йомыркалар бирәмесез?
Йомыркалар бирмәсәгез,
Тимер тукмак алырбыз,
Савыт-сабаң ярырбыз,
Йомыркалар бирсәгез -
Тавыкларыгыз кытласын,
Кытласын да кыртласын,
Иләк-иләк йомырка.
Кыт-кытыйк!
Кыт-кытыйк (3, 29 б.).

Ярма-майларны җыеп бетергәннән соң, яшьләр авыл читенә, тау башына, су буена яки башка авыл халкы җые-

ла торган берәр урынга юнәлгән. Анда казаннар асканнар, авыл карчыклары җыелган ризыклардан ботка пешергәннәр. Яшьләр ул вакытта төрле уеннар уйнаган.

Себер татарларында ботка пешерер өчен ярма, майларны өйдән-өйгә кереп җыймыйча, һәркем үзе белән сөт, ярма яки май алып килгән. Карга боткасын абзар түбәләренә, печән өсләренә менеп утырып ашаганнар.

Кара каргаларга аш булсын,
Ала каргаларга таш булсын, - дип

каргалар өчен багана башларына кашык белән ботка салып чыканнар (1, 209 б.).

Д.Б. Рамазанова язып алган материалларда да Себер татарларының "карга боткасы" йоласы тасвирлана. Яшьләр алып килгән ризыкларны берәр әби өендә пешереп биргән. Ботканы абзар яки сарай түбәсенә менеп утырып ашаганнар.

"Карга боткасы" йоласы белән бәйле текст шаян рухта, ул соңгы чорлар иҗаты булырга мөмкин:

Карык-карык каргалар,
Кар өстендә йөргәләр,
Ботка өстендә май күрсәләр,
Әхкәм укыр муллалар (7, 20 б.).

Ботка пешеп чыккач, беренче аш итеп җиргә сый биргәннәр, барысы бергә учлап җиргә ботка сипкән, чишмә суына корбан иткәннәр. Аннары үзләре ашаган (3, 29 б.).

Р.Ф. Ягъфәров карга боткасы ашауның икенче төрен күрсәтә: "Бәйрәм берләшеп ботка ашау белән тәмам булган. Калган ботканың бер өлешен җир-су ияләренә дип, җиргә салып калдырганнар, ә бер өлешен авылга алып кайту мәҗбүри булган. Чөнки аңардан авылның барлык кешеләре дә авыз итәргә тиеш булган. Халыкта "карга боткасы" ашаган кеше ел буена сау-сәламәт була, авырмый дигән ышану яшәгән".

Славян халыкларының язны чакырып камырдан төрле кошлар пешерүе турында алдарак әйтелде. Бу йола татарларда да булган. Карга боткасына камырдан кошлар пешергәннәр. Бу турыда мәгълүматлар аз булса да бар. Мәсәлән, Ф.С. Баязитованың Свердловск өлкәсе татарларының рухи мирасына багышланган китабында түбәндәге мәгълүмат бар: "Баркылдак (сыерчык) безе китсен дип, әни арыш оннан баркылдак ясап пешерә иде, кош формасы итеп ясап. Күз урыны ясап, корот кап шартлама (җир җиләге) тыгып бирә иде. Гел яратабыз без аны. Аннан шуны карга боткасы вакытында алып барып ашый торганнар иде" (1, 118 б.).

Фрагментлар рәвешендә генә сакланып калган материаллардан чыгып фикер йөрткәндә дә "карга боткасының" яки "карга туеның" язны алып килүче кара каргаларны олылаучы йола икәнлеге аңлашыла. Кара каргалар килгәнне күргән кешеләр яз җитүгә, җир уянуына ышанганнар. Шул ук вакытта, уяныш килүче җирнең мул уңыш бирүен теләп, төрле ритуаллар үтәлгән. "Йомырка тәгәрәтеп уйнау, карга, тавык булып кылану, ботканы җиргә сибү - болар барысы да алдагы уңышның мул булуын теләүгә кайтып кала. Кайбер очракта җир-анага табыну, усал көчләрнең суга-җыр ярдәмендә "күңелен" күрергә тырышу омтылышлары да аңгырап кала" (3, 30 б.).

Р.М. Мөхәммәтҗанов "карга туе" йоласы вакытында "Шайкамыш", "Кабыргалы камчылы", "Ахшару" дигән уеннар уйналуын әйтә. Галим әлеге уеннарның игенчелек һәм никах йолалары белән бәйле тамырларын күрсәтә (3, 30 б.).

Карга туеның борынгыларда тагын да тирәнрәк тамырлары булуын да кире кагып булмый. Кошлар мифологиядә җан символы. Үлгән кешенең җаны кошка әверелеп оча ала дип ышанганнар (2, 348 б.).

Көз көне кара каргалар, җирләр туңып, кар ява башлагач, соңгы булып китә. Алар киткәч, кыш башлана. Ягъни җирнең тереклек билгеләре күренми, үләннәр үсми, агачлар яфрак койган, елга-күлләр боз белән каплана. Димәк, борынгылар аңында җир үлә. Аның үлүен кара каргалар белән бәйләп карганда, җирнең җаны кара каргалар булып китә. Ә аз көне шул ук кара каргалар яңадан җиргә җан алып кайта - җир терелә.

Каргаларны изгеләштерү, алар кайтуны бәйрәм итү йоласы бик борынгы заманнардан каргаларның җиргә җан алып кайтуы белән бәйле булырга мөмкин.

### *Әдәбият*


1. *Баязитова Ф.С. Урта Урал (Свердловск өлкәсе) татарлары: рухи мирас, гаиләкөнкүреш һәм йола терминологиясе, фольклоры. - Казан, Фикер, 2002.*
2. *Мифы народов мира. Энциклопедия в двух томах. Гл. ред. С.А. Токарев. - М., Советская энциклопедия, 1982. – Т. 2.*
3. *Мөхәммәтҗанов Р.М. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (календарь поэзия). Татар халык иҗаты курсы буенча уку әсбабы. – Уфа, Башкортстан дәүләт университеты нәшрияты, 1982.*
4. *Надыров И.Н. Йола поэзиясе, татар фольклоры жанрлары. – Казан, 1978.*
5. *Никитина В.Б. Литература Ирана. Литература Востока в средние века. Ч. II. – М., 1970.*
6. *Пропп В.Я. Русские аграрные праздники. Опыт историка этнографических исследований. – М., Лабиринт, 2004.*
7. *Рамазанова Д.Б. Себер диалектларыннан материаллар. – Казан, Фикер, 2001.*
8. *Традиционные обряды и обрядовый фольклор русских Поволжья. Составители Г.Г. Шаповалова, Л.С. Лаврентьева. Под ред. Б.Н. Путилова. – Ярославль, Наука, 1985.*
9. *Ягъфәров Ф.Ф. Татар халкының уен фольклоры. – Казан, Иман, 2002.*